БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА

# ТАТАР ТАҖЫ

X — XVlll гасырларда яшәгән олуг кешеләр турында нәни хикәяләр

КАЗАН ı «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ ı 2004

УДК 94(47.41) : 821.512.145-32
ББК 66.3(2Рос=Тат)8:84(2Рос=Тат)6-44
З-87

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Рәссамнары:
*Рушан һәм Рэм Шәмсетдиновлар*

**Зәйдуллин Р. Р.**

Татар таҗы: X—XVIII гасырларда яшәгән олуг кешеләр турында нәни хикәяләр/Ркаил Зәйдулла.— Казан: Мәгариф, 2004.— 103 б.

ISBN 5-7761-1421-7

Әлеге китап вакыт ягыннан X—XVIII йөзләрне колачлый һәм татар халкының таҗы булган олуг шәхесләр — дәүләт ирәннәре, шагыйрьләр, халык күтәрелеше юлбашчылары турында бәян итә.

ISBN 5-7761-1421-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2004
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2004

## Татарстан

*Ярсып килгән дошман явы,*
*Дошман безне аткан, аскан.*
*Буйсынмаган беркайчан да*
*Татарстан, Татарстан!*

*Абынсак та, егылсак та,*
*Без ул — аягүрә баскан.*
*Ярдәм итсен безгә Алла,*
*Татарстан, Татарстан.*

*Азатлыктан яздырырга*
*Беләзекне богау кыскан.*
*Күңелләргә богаулар юк,*
*Татарстан, Татарстан.*

*Томырыла аргамаклар,*
*Узганыбыз — гүзәл дастан.*
*Кузгалабыз изге юлга,*
*Татарстан, Татарстан!*

# Алмыш илтабар

(X гасырның беренче яртысы)

Мең еллар элек без яшәгән җирләр Болгар иле дип аталган. Монда Алмыш исемле кеше патшалык иткән. Ул вакытта безнең бабайлар патшаны илтабар дип атаганнар.

Болгарларның күбесе мөселман булган. Тик Алмыш үзе ислам динендә түгел икән әле. Менә беркөнне ул төш күрә. Төшендә ниндидер ягымлы тавыш ишетә: «Алмыш! Халкың белән бер диндә бул!»

Алмыш бөтендөнья мөселманнарының башлыгы Багдад хәлифәсенә илчеләр җибәрә. Сезнең галимнәрегез безне дингә өйрәтсеннәр, мәчетләр салырга булышсыннар, дип хат юллый.

Менә Багдадтан хәлифә илчеләре кәрван белән Болгарга кузгала. Анда биш меңләп кеше, өч мең чамасы ат, бик күп дөяләр була. Алар илтабарга Багдад хәли-фәсеннән бүләкләр дә алып киләләр. Иң зур бүләк Коръән китабы һәм иярләнгән ат икән.

Алмыш илчеләрне башкаласыннан чыгып каршы ала. Янындагы кешеләре илчеләргә алтын-көмеш тәңкәләр чәчә.

«Моннан соң без мөселман иле булырбыз!» — ди Алмыш.

Биредә бераздан илнең бөтен халкы җыела. Барысы да бер булып кабатлыйлар: «Лә илаһи иллә Алла, Мөхәммәде рәсүлулла». Мөселман булыр өчен иң башта шул сүзләрне әйтергә кирәк.

Иң алда Алмыш илтабар басып тора. Аның йөзе көләч. Үзенең дә, халкының да мөселман булуына сөенә ул. Аллабыз безгә дус яшәргә, бай булырга, дошманны җиңәргә ярдәм итәр, дип уйлый.

Ә дошманнары күп була Болгар иленең. Калаларга урман халыклары һөҗүм итә, елга юлбасарлары сәүдә көймәләрен талый... Алмыш илтабар Алладан ярдәм сорый, хак динебез безне бердәм итсә иде, дип ялвара. Чөнки ул белә: **халык бер йодрык булып укмашса, ил беркайчан да җиңелми.**

Бүген дә мәчетләрдән азан авазы яңгырый.

Дога кылганда, борынгы Алмыш бабабызны искә алыйк!

* * *

«Халык белән бер тиң бул!» —
Яңгыраган бер тавыш...
Бисмилланы кабатлап,
Намазга баскан Алмыш.

Кешеләрнең йөрәге
Сөенечтән кысылган,
Дөньяга хәбәр киткән:
«Без барыбыз мөселман!»

## Кол Гали

(1183—XIII гасырның беренче яртысы)

Затлы сарай эчендә, атлас мендәрләргә башын куеп, Таймус патшаның кызы Зөләйха йоклап ята. Аның төшенә гаҗәп сылу гәүдәле, матур йөзле егет керә. Кыз аңа шунда ук гашыйк була. Егет тә аңа мәхәббәтен аңлата, үзенең исә Мисыр патшасы булуын белдерә.

Ашау-эчүдән калган, йокысы качкан кызын Таймус патша Мисыр хөкемдарына кияүгә бирергә ризалаша. Әмма кияүне күргәч, Зөләйха куркып кычкырып җибәрә: чибәр егет урынына аны бер карт каршы ала. Кайда ул төшкә кергән асыл егет? Кайда Йосыф?

Йосыфның белемле, акыллы, чибәр булуыннан көнләшеп, бертуган агалары коега салалар. Аннан егетне кәрванчылар коткара, үзләре белән Мисырга алып китә. Анда Йосыфны патшага кол итеп саталар. Белеме, сабырлыгы, игелеге аркасында, Йосыф тиздән үзе патша була. Күп маҗаралардан соң алар Зөләйха белән кавышалар.

...Кол Гали, алҗып, каурый каләмен кәгазьләр өстенә куйды. Борын-борын заманнарда булган вакыйгалар аны үзенә бөтереп алган иде. Гасырлар аша исүче сахра җиле кузгаткан күңелен басар өчен, шагыйрь бүлмәсе буйлап ары-бире йөри башлады. Бүләр шәһәре инде уянып килә. Офыкта берәм-берәм йолдызлар сүнә башлады. Еракта алтын төлке җемелдәп торган калын койрыгын кымшатып куйды. Урамда базарга баручы сәүдәгәрләрнең аяк тавышы ишетелде. Менә дистәләгән мәчет манараларыннан азан яңгырады. Шагыйрь почмакта торган комганына үрелде.

Белемнең кешене бәхеткә илткәнен, сабырлыкның максатка җиткергәнен, туганлыкның изге, мәхәббәтнең бөек булуын аңлармы бу «Йосыф китабы»н укучылар? Шагыйрь, ашыгып, янә кәгазьләре өстенә иелде. Каударланып, каурый каләм кыштырдады:

Шушы шигырь кыйммәтен ахмак белмәс,
Акыл моны тыңлар, аңлар, белер имди.

Сигез йөз елга якын Кол Галинең бу китабын татар халкы яратып

укыды, Йосыф-Зөләйханың мәхәббәтенә сокланды. Димәк, үз халкының акылына ышанган шагыйрь хаклы булган икән. Ә без — хәзергеләр — киләчәккә барганда, бу гүзәл китапны җуймабызмы? Хәер, **«шигырь кыйммәтен белмәс» ахмак халыкның киләчәге дә булмый**.

* * *

Дөнья бит бу — шигырьне дә
Оныткан чак булгалый.
Тарих төпкеленнән шулчак
Бармак селки Кол Гали.

# Бату хан

(якынча 1207—1256)

Ул көнне Чыңгыз хан бераз сырхаулап тора иде. Шулай да урыныннан торды, биек тәхетенә килеп утырды.

— Оныгым Батуны чакырыгыз! — дип кычкырды ул.

Күп тә үтмәде, урта буйлы, киңрәк йөзле бер егет тирмәгә килеп керде дә тәхет алдында тезләнде.

— Ни боерасың, бабам? — дип сорады ул.

Чыңгыз хан, оныгына карап, берара сокланып торды. Аерата якын күрә иде ул бу турунын.

— Минем улым, синең әтиең Жучи үлде,— дип сүз башлады хан.— Мин аңа Себердән Дунай елгасына кадәр җирләр биргән идем. Хәзер ул җирләр — синеке!

— Анда бит кыпчаклар, болгарлар, урыслар яши,— диде Бату.— Алар безгә буйсынмый.

— Яулап алырсың,— дип елмайды Чыңгыз хан.— Алар безгә ялчы булырлар.

**Җиңүчеләр җиңелгән халыкны һәрвакыт ялчы итә**.

Бату хан яуга кузгалды. Меңнәрчә атларның тояк тавышыннан дала гүләп торды. Яугирләрнең ярсу авазыннан кошлар куркып һавага күтәрелде, җәнлекләр ояларына посты.

Бату гаскәре Үзи (Днепр) елгасы янына килеп җитте. Каршыда Ханкирмән шәһәре (Киев) җәелеп ята. Бату калага илчеләр җибәрде.

— Бирелсеннәр, без аларга тимәбез,— диде ул.— Илчегә үлем юк.

Тик Киев кешеләре татарларның бу мәкален белми иде, илче-

ләрне үтерделәр. Ачуы чыккан хан кирмәнне яулап алды. Исән калган кыпчаклар, урыслар Мадьяр (венгр) иленә качтылар. Бату анда да аларны тар-мар итте.

— Бөтен Аурупаны басып алыйк! — диде гаскәр башлыгы Субудай.

— Күп сугыштык, хәзер үзебезнең ил-йортыбызны корабыз,— диде Бату.

Гаскәр кире борылды. Башта Бату Болгарга килеп, анда берничә ел яшәде. Аннары Иделнең түбән өлешенә төшеп, үзенә ошаган урынга туктады.

— Менә бу урын Алтын таш булыр, монда минем сараем торыр! — дип әмер бирде.

Бу башкала Сарай-Бату дип аталды. Бату иксез-чиксез иле белән шул шәһәрдән торып ханлык итте.

* * *

«Илем мәңге яшәр!» — диеп,
Бату тәхеткә менә.
Ни әйтергә тели икән? —
Янда Идел көрсенә...

## Бачман

(XIII гасыр урталары)

Ул хәлләрдән соң җиде гасырдан артык вакыт үткән. Ә Идел елгасы барысын да хәтерли әле. Яр буендагы җикән камышларның пышылдавына колак салыгыз: алар тын гына сыкрап: «Бачман, Бачман»,— дип иңриләр сыман.

Көнчыгыштан моңарчы күз күрмәгән яу килгән. Йонлач атларга атланган яугирләр, кыпчакларны, болгарларны җиңеп, кояш баешына таба ыргылганнар. Ул вакытта безнең бабайлар кыпчаклар, болгарлар дип аталган.

Халык илбасарларга буйсынып яшәргә мәҗбүр булган. Ләкин шул чакта Бачман исемле каһарман егет даланы яңгыратып кычкырган: **«Тезләнеп яшәгәнче, аягүрә үлүең мең мәртәбә артык!»** Һәм башбирмәс баһадирлары белән илбасарларга каршы сугыша башлаган. Далада уклар сызгырган, сөңгеләр суырылып очкан, атлар кешнәгән.

Бачманның егетләре илбасар ханнарның исәпсез-сансыз гаскәренә көтмәгәндә һөҗүм итә икән дә, тегеләр аңга килгәнче,

Идел буендагы урманнарга кереп яшеренә икән. Үз егетләрен шулай итеп Идел дә, урманнар да саклаган.

Ләкин илбасар хан Мәңге Тимер дә хәйләкәр булган, ул бер сатлык җан аша Бачманның кайда яшеренгәнен белеп алган. Аяусыз сугышта Бачман дошман кулына әсир төшкән.

— Хан алдында тезлән! — дигән аңа Мәңге Тимер.— Батырлыгың өчен исән калдырырмын.

— Килмешәк хан алдында тезләнергә мин дөя түгел,— дигән горур каһарман Бачман.— Үз җиремдә үлем дә татлы...

Мәңге Тимернең ишарәсен күрүгә, алып гәүдәле яугире кылычын күтәргән...

Ул хәлләрдән соң инде җиде гасырдан артык вакыт үткән. Идел һаман ага да ага. Җикән камышлар «Бачман, Бачман...» — дип пышылдыйлар сыман. Безгә ни әйтергә тели икән алар?

* * *

Бачман кебек батырны
Тезләндермәс бер түрә...
Дошманга баш биргәнче,
Үлә ул аягүрә.

## Үзбәк хан

(1282—1342)

Сарай шәһәре турында ишеткәч, гарәп сәяхәтчесе ибне Баттутаның аны барып күрәсе килде. Менә ул атаклы Сарай шәһәрендә! Бу вакытта татар илендә Үзбәк ханлык итә иде. Ибне Баттута шәһәр читендәге кәрвансарайга урнашты. Иртәнге намазны укыганнан соң, ул шәһәрне күрергә китте. Сарай шәһәре бик зур иде, аның икенче очына ул кичкә генә барып чыкты.

Ибне Баттута дәфтәренә болай дип язып куйды: «Сарай шәһәре — Җир йөзендәге барлык шәһәрләрнең иң гүзәле, иң зурысы. Кеше күп. Урамнары киң, базарлары бай. Сарайда унөч зур мәчет бар, кечкенә мәчетләрнең исәбе юк».

Ибне Баттутаны Сарайның галим кешеләре белә иде, алар аны Үзбәк хан янына алып бардылар.

— Кунакларга бездә урын түрдән! — диде хан.— Сарай ошадымы үзеңә?

— Гүзәл шәһәр,— диде сәяхәтче.

— Илебездә иминлек, юлларда тәртип, кешеләр мул яши... — Үзбәк хан бераз мактанып алды: — Алтын төяп, япа-ялгыз илне буйласаң да, башыңнан бер бөртек чәч төшмәс.

**Илнең көче — шәһәрләрдә!**

Шул чакта сарайга бер морза йөгереп керде. Ханның колагына нидер пышылдады.

Ибне Баттута чыгарга борылды. Үзбәк аны туктатты.

— Тик илебездә мөселман булмаган җирләр дә бар шул,— диде ул.— Менә урысларның Тверь шәһәрендә мөселман сәүдәгәрләрне, һөнәр ияләрен үтергәннәр. Исерәләр дә азып тузалар.

Ибне Баттутаның урыс дигән халыкны ишеткәне юк иде. Ләкин аны ханга әйтеп тормады.

— Иванны чакырыгыз! — дип кычкырды хан.

Ишектән Калта кушаматлы Мәскәү кенәзе килеп керде дә тәхет каршында тезләнде.

— Тыңлыйм һәм буйсынам! — диде ул.

— Тверь халкы, азып-тузып, бер гаепсез кешеләрне үтергән, шуларга сабак биреп кайт! Илле меңлек гаскәр бирәм.

— Тыңлыйм һәм буйсынам,— дип янә кабатлады кенәз.— Мәскәү сезнең сүздән беркайчан да чыкмас!

* * *

Әйтте Үзбәк: «Шушы ил-йортны мин
Ислам дине белән яңарттым.
Сезгә кала хәзер. Нык торыгыз,
Ике улым — ике канатым».

## Котби

(XIV гасырның беренче яртысы)

Иксез-чиксез татар илендә хисапсыз шәһәрләр булган. Анда мәчетләрнең манаралары күккә терәлгән, базарлар гөрләгән. Иң гаҗәбе: бу шәһәрләрдә барысы да татарча сөйләшкән. Яһүдләр дә, әрмәннәр дә, урыслар да һәр үтеп баручы угыл-кыздан: «Ни телисең?» —дип сорап калган. Чөнки ул вакытта татарлар дәүләт тоткан.

**Дәүләтле халыкның бөек шагыйрьләре дә була**.

Алтын Урда ханы Үзбәкнең өлкән углы Тәнибәк сараенда мәҗлес бара. Мишәр урманнарыннан хан хозурына «Хөсрәү вә Ширин» дигән гүзәл әсәрен алып килгән Котби шул дәвернең

шәүләсен безнең көннәргә кадәр китереп җиткергән:

Баһадирлар олугы курчылыкта,
Егетләр күреклесе бавырчылыкта.

Ягъни батырлар яу белән, егетләр табын җыеп, иминлек белән дан ала. Егетләр дигәндә, хәзерге татарларны күздә тоткандыр ул.

Тәнибәкнең Мәликә исемле хатыны да була. Ул аны бик ярата. Бөек шагыйрь Котби аны искәртә:

Гашыйклык белән шатлык — рас килмәс,
Ике эшнең берсен кыл — юкса булмас...

Соңыннан ил өчен түгел, көн өчен яшәүче бай морзалар Тәнибәкне үтерәләр, һәм, әлбәттә, аның дусты Котби дә исән калмый.

Әмма шагыйрьләрдә бер сер бар — аларның үзләреннән соң да сүзләре яши. Ханнар белән дус булса да, Котби алдан ук әйтеп куйган:

Ни эт җанлы кеше мин — ирек белмән,
Ки ошбу монда ялгызлыктан үлмән.
Дөньяда этнең урыны бар — мәнем юк,
Нә адәм углымын, этчә саным юк...

Бөек шагыйрьләр эчендәгесен яшерми.

* * *

Котби тапкан бу чишмәгә
Тидергәч тә иренне,
Сөю утында янарга
Терелттем мин Ширинне.

# Мәхмүд Болгари

(?—1360)

Сарай шәһәренә тагын яз килде. Түбәләрдә чыпчык-

лар чыркылдый, яз хәбәрчеләре — кара каргалар вакыт-вакыт аваз салып куя.

Шәех Мәхмүд бине Гали үз мәдрәсәсеннән өенә кайтып бара иде. Уенчак язгы һава сулыш юлларын кытыклап рәхәтләндерсә дә, бүген ул иртәдән бирле кәефсезләнеп тора әле. Шуңа да, таягына таянып, янә туктап калды. Сул кулын каш өстенә куеп, зәп-зәңгәр күккә күз салды. Анда кая табадыр киек кошлар очып бара иде.

«Гомер узды да китте»,— дип уйлады галим. Әле кай-чан гына Болгардан башкалага белем алырга килгән иде бит. Ул чагында бер яшүсмер генә иде әле ул. Әтисе Гали белән бабасы Гомәр аны Идел ярына кадәр озата бардылар. Алар икесе дә Болгарның атаклы шәехләре — дин башлыклары иде. Елга корабы аны Сарай шәһәренә алып китте.

...Урамнан һай-һу кычкырып, дистәләгән дала яугире җилдереп үтте. Шәехкә сәлам бирергә дә оныттылар. «Тагын хан алмаштыралар, ахрысы»,— дип ачынып уйлады ул. Татар иле болгана, ата улны, ана кызны танымый башлаган иде.

Ә бит аның болгана башлаячагын моннан ике ел элек үк сизенгән иде Мәхмүд шәех. «Нәһҗел-фәрадис» дигән китабын шуңа язды да ул. «Нәһҗел-фәрадис» — оҗмахның ачык юлы, димәк...

Шул китап турында ишетеп, яңа гына тәхеткә менгән Бирдебәк хан Мәхмүд шәехне үз сараена чакырды. Аның турында: «Әтисе Җанибәкне үтертеп, хан булды»,— дип сүз чыккан иде.

— Йә шәех, син оҗмахка илтәсе юлны беләсең, дип ишеттек, безгә дә күрсәт,— диде хан.

Мәхмүд бине Гали, китабын актарып, «Бала һәм ата» дигән хикәяне тапты. «Ата-анага хөрмәт күрсәтү, аларны олылау савабы намаз уку, ураза тоту, хаҗга бару савабыннан да өстен»,— дип укыды ул.

Бирдебәк көлде:

— Ялгышасың, шәех,— диде ул.— Алла көчлене яклый.

**Хан белән шагыйрьнең сүзе беркайчан да уртак булмый**.

Мәхмүд Болгари тагын күккә күз салды. Күк гөмбәзе акрын гына аска төшә сыман тоелды. Шагыйрь елмайды. Ни күрде икән ул төпсез күк йөзендә?

Бу —1360 елның 22 марты, якшәмбе көн иде...

* * *

Каш өстенә кулын куеп,
Иле өчен юл карый,—
Ничә гасыр гаделлеккә
Өнди Мәхмүд Болгари.

# Сәйф Сараи

(1321—1396)

Илнең яме китте. Морзалар, бәкләр бер-берсе белән сугышалар, тәхеткә әле бер хан, әле икенче хан менә. Алтын Урда башбаштакка әйләнде.

Сәйф Сараи мәдрәсә тәрәзәсеннән урамга күз салды. Тояк тавышлары ишетелә. Тагын даладан берәр хан сарайга һөҗүм итәме? Тик шагыйрь тышта берни дә күрмәде. Әллә тәрәзәне тузан каплаган, әллә күзен яшь томалаган...

Ә бит ничә еллар элек кенә Сарай дошманнарны көнләштереп гөрләп тора иде. Мәчет манараларыннан моңлы азан тавышы ишетелә, мәдрәсәләргә шәкертләр агыла, базарлар кайный. Анда кемнәр генә юк... Кытай сәүдәгәре ефәк тукымаларын мактый, һиндус кулында асылташлар, рум кешесе затлы савытлары белән мактана, болгар үзенең болгари күнен җәеп салган, кыпчак чабыш атлары алып килгән...

Сәйф бирегә Камышлы шәһәреннән укырга дип килде. Мондагы мәдрәсәләрдә дөньяның атаклы галимнәре укыта иде.

Камышлы йорт минем туган илем иде,
Белең: чит якка китергән — белем иде.

Аннары ул үзе мәдрәсәдә укыта башлады. Кыйссалар, шигырьләр язды. Шигырьләрен тыңларга ханнар үзләре аның бүлмәсенә килә иде.

Үзбәк хан, Җанибәк хан...

Һәр шигырьдән Сәйф Сараиның җан авазы ишетелде: гадел булыгыз, йортны имин тотыгыз!

Алтын Урдадан дошманнар кан калтырап тора иде...

Хәзер татарлар бер-берсенә кылыч күтәрә...

Кулларда каләм түгел хәзер, кулларда — сөңге, кылыч...

Мәдрәсә каршына көймәле арбага җигелгән атлар килеп туктады. Хезмәтчеләр төрле төенчекләр ташый... Сәйф Сараи дога кылып кузгалды. Аңа хатыны, балалары иярделәр.

Илен ташлап, Мисырга китә шагыйрь. Мисырның солтаны — кыпчак — шагыйрьне иленә чакырган...

**Кадерсез йорттан кот кача**.

Сәйф Сараи ашыга-ашыга язып куйды:

Үсте туфракта үзгә сөңгеләр, мин өйдән аерылдым,
Ватаннан хәбәрсез булдым да үзгә йортка әвереледем.
Нигә язмыш җәбер итте соң, нинди гөнаһым бар?!
Илаһи, нигә җәберең, мин илгә тугры ул идем.

Шагыйрь китте. Әле тагын күпме шагыйрьләрнең туган илдән аерыласы бар...

* * *

А-и, а-и... Идел акчарлагы
Яраланган, дәшә: а-а-и...
Мисырга ук ишетелә икән! —
Елый, елый Сәйф Сараи.

# Туктамыш хан

(якынча 1350—1406)

Үзбәк ханның уллары Тәнибәк белән Җанибәк үлгәч, Алтын Урдада гауга башланды. Чыңгыз хан нәселеннән булган һәркем тәхеткә менәргә теләде.

Иделнең уң ярындагы кыпчак далаларында, Кырымда, Үзи (Днепр) буйларында Мамай морза идарә итә иде. Ул Сарайдагы ханнарга буйсынмый, кайчагында аларны тәхеттән бәреп тә төшерә.

Беркөнне Мамай Мәскәү кенәзенә хат җибәрде: «Син ясакны Сарай ханына түгел, миңа түлә!»

Тик Мәскәү кенәзе аны тыңламады, ул Сарайдагы ханнан курка иде.

— Яуга! — дип кычкырды ярсыган морза. Кырымдагы итальяннарны, Кавказдагы чиркәсләрне җыеп, Мәскәү өстенә китте. Тик алар анда урысларны җиңә алмадылар. Мамайның ялланган гаскәре таралды.

Сыгнак дигән шәһәрнең башлыгы Туктамыш, бу хәбәрне ишеткәч, бик гарьләнде. Гаскәре белән Сарай шәһәренә килде.

— Хәзер сезнең ханыгыз мин булам! — диде ул.

Башбаштак морзалар, бәкләр, куркынып, аңа баш иде. «Ханнарны күргән бар,— дип уйлады алар.— Ничә көн утыра алырсың икән тәхеттә?..»

— Ике тәкә башы бер казанга сыймый! — Хан үзенең гаскәрен Мамай өстенә алып китте.

Мамай гаскәре, Туктамышны күргәч, атларыннан төшеп, чын ханга баш иде. Мамай качты.

— **Без бердәм булсак, дошман куркып торыр!** — дип, Туктамыш хан Мәскәү өстенә кузгалды.

Моны ишеткәч, Мәскәү кенәзе Дмитрий каядыр чыгып качты, ә шәһәр халкы, хан килүенә капкаларны ачып, аны ипи-тоз белән каршылады.

Туктамыш ханның даны бөтен дөньяга таралды. Аны Насретдин Баһадир хан дип зурладылар.

Бу турыда Сәмәрканд әмире Аксак Тимер дә ишетте, Туктамыш ханның данынннан көнләште. Аксак Тимер инде аңарчы ярты дөньяны яулап алган иде.

Туктамыш ханның хыянәтче морзалары Аксак Тимергә хәбәр җибәрделәр. Без сиңа ярдәм итәрбез, диделәр.

Менә сугыш башланды. Аксак Тимер һөҗүмгә күчкәч, Туктамышның сатлык морзалары сугыш кырыннан качып киттеләр. Туктамыш җиңелде. Алтын Урда таркалды.

* * *

Данлыклы Сарайда бүген
Калмаган сыңар түбә.
Ни сулкылдый буш далада?
Туктамыш хан яшь түгә...

# Идегәй

(1352—1419)

Аксак Тимер яуларыннан соң Алтын Урда шәһәрләре хәрабә хәлендә калды, кыпчак даласы үзе дә батыр яугирләрен сагынып сыкрый төсле иде.

Идегәй морза җимерелгән Сарай шәһәренә килде. Төрле якка таралган батырларны үз янына җыйды. Чыңгыз хан нәселеннән булган Тимер Котлы да аның янәшәсендә иде.

— Алтын Урданы тагын бер кулга җыябыз,— диде Идегәй.— Тимер Котлы! Син — хан, ә мин синең гаскәр башлыгың булырмын.

Идегәй кул астына бихисап гаскәр җыелды.

Туктамыш хан, бу турыда ишеткәч, үз-үзенә урын тапмады. Аксак Тимер яуларыннан соң ул Литва иленә киткән иде.

— Идегәй минем тәхетемне тартып алды,— диде ул.

— Минем гаскәрем күп! — дип мактанды Литва кенәзе Витовт.— Мин сине Алтын Урда тәхетенә утыртырмын. Син миңа шуның өчен Мәскәү илен бирерсең.

Менә ике гаскәр Бурсыклы елгасы ярында очрашты.

— Бирелегез! — дип кычкырды Литва кенәзе.— Күрәсезме минем гаскәремне? Монда Аурупа рыцарьлары, поляклар, литвалар, урыслар. Без сезне сытабыз!

Идегәй Тимер Котлыга, үз гаскәре белән шыпырт кына, дошманның артына төшәргә кушты.

— Син яшь әле! — дип кычкырды ул Литва кенәзенә.— Миңа «атам» дип эндәш, акчаларыңа минем исемне сук! Шул чагында кичерермен...

Витовт ачуыннан ярсып оран салды:

— Яу!

Далада туплар гөрселдәде. Литва гаскәре һөҗүмгә күтәрелде. Идегәй гаскәре юри чигенә башлады. Һөҗүм итүчеләрнең сафлары таркалгач, алар дәррәү алга ташландылар. Тимер Котлы дошманның артына төште.

Литва гаскәре тәмам тар-мар ителде, бик азлар гына үз илләренә кайтып җитә алды.

Туктамышның уллары күп иде. Алар һәрберсе Идегәйдән үч алырга сүз бирде.

Ләкин Идегәй аларның һәрберсен берәм-берәм җиңә торды.

Менә берзаман Туктамышның тагын бер улы Кадыйр Бирде гаскәре белән Идегәйгә каршы чыкты.

Татарлар бер-берсенә каршы сугыша башладылар. Бу сугышта Идегәй дә, Кадыйр Бирде дә һәлак булды.

**Ызгышлы ил бәхетле булмый**.

* * *

Сагыш белән тулган йорт —
Идел — Җаек арасы.
Җаныбызда һаман сызлый
Идегәйнең ярасы.

## Олуг Мөхәммәд хан

(якынча 1405—1445)

Иксез-чиксез татар дәүләте — Алтын Урда! Сарай — аның башкаласы. Заманында гөрләп торган зур шәһәр булган ул, иркен биналары, гүзәл мәчетләре, күз явын алырлык бакчалары белән дан тоткан.

Хан сарае Алтын таш дигән мәйданга урнашкан. Тәхеттәге хан илчеләр кабул иткән, гаскәрен яуга җибәргән, күңеленә ошаган

кешеләргә ярлык өләшкән.

Ләкин хан булырга теләүчеләр күп булган. Әле берсе, әле икенчесе тәхеткә күтәрелгән. Төшерелгән ханны җәза мәйданына алып чыгып, башын чапканнар. Җәза мәйданы Салкын таш дип аталган. Менә беркөнне кодрәтле Олуг Мөхәммәд ханны да тәхеттән бәреп төшерәләр. Ул өч меңлек гаскәре белән Сарайдан урыс җирләренә кача.

— Безнең җирләрдән кит! — ди аңа Мәскәү кенәзе Василий.

— Мин Сарай ханы чагында сине Мәскәү кенәзе итеп күтәрдем, дошманнарыңнан сакладым,— ди Олуг Мөхәммәд.— Син хәзер ашка таш белән атасыңмы?

— Ул вакытта син хан идең, ә хәзер — качак...— Урыс кенәзе шаркылдап көлә.— Гаскәр белән килеп, сине дә, кешеләреңне дә юк итәм!

Олуг Мөхәммәднең өч мең яугире кырык меңлек урыс гаскәре белән сугыша башлый. Иң алда ханның өч улы — Мәхмүд, Якуб, Касыйм кылыч уйната. Алар, майга батып кергән пычак кебек, дошман гаскәрен икегә бүлеп ташлыйлар. Мәхмүд Мәскәү кенәзе Василийны аттан бәреп төшерә. Урыслар, моны күргәч, Мәскәүгә борылалар.

— Син минем әсир! — ди Олуг Мөхәммәд һәм Мәскәү кенәзен үзе белән Казан каласына алып китә.

— Коткар гына,— дип ялвара аңа Василий.— Ни телисең, шуны бирәм — алтын-көмеш, атлар, сугыш кораллары...

**Атлы ир-ат җәяүлегә юлдаш булмас!**

— Менә минем илем! — Олуг Мөхәммәд, аны ишетмәгән дә кебек, кулы белән җәйрәп яткан елга-күлләргә, офыкта зәңгәрләнеп торган урманнарга, ат дугасын күмеп китәрдәй биек, куе печәнле болыннарга күрсәтә.— Менә минем башкалам Казан! Син үзең дә, балаларың-туруннарың да мәңгегә бу калага буйсынып торыр, ясак түләр. Ә хәзер бар, шул турыда кайтып боярларыңа сөйлә.

— Мең яшә, бөек хан! — ди Василий.— Мәңге шулай булыр, без антны бозмабыз!

Һәм ул, башын иеп, үз иленә кузгала. Якуб белән Касыйм аны Мәскәүгә кадәр озатып баралар.

* * *

«Без күбәү!» — диеп, дошман килгәндә,
Урап алганда җанны кыямәт,

Тураеп басам, исемә төшә
Белев сугышы, Олуг Мөхәммәд.

## Мәхмүд хан

(?—1467)

Казан шәһәрендә сарайлар, мәчетләр калкып чыкты. Гади халык та урыс-улак һөҗүменнән курыкмый башлады. Югыйсә алар, Идел буйлап көймәләрдә төшеп, һәр елны шәһәр-авылларны талыйлар иде.

Мәскәү кенәзенең моңа бик ачуы килде.

— Мин Казанга буйсынмыйм, ясак түләмим,— дип лаф орды ул.

Моны ишеткәч, Олуг Мөхәммәд гаскәре Түбән Новгородны яулады. Ә улы Мәхмүдне хан Мәскәү ягына юллады.

Тәкәббер Василийның исәпсез гаскәре аларга каршы чыкты. Суздаль шәһәре янындагы бу канлы сугышта урыслар җиңелде, ә Мәскәү кенәзе үзе татарларга әсир төште. Аның муенындагы алтын тәресен салдырып, Мәскәүгә җибәрделәр. Кенәзләренең әсир төшүен ишеткәч, Мәскәү халкы нык кайгырды. Ул көнне чиркәү-ләрдә чаң кактылар, кешеләр урамда елашып йөрде.

Василий үзе дә зинданда елап утыра иде. Ыңгырашып ишек ачылды. Кинәт кергән яктылыктан кенәз сукырайгандай булды, күзләрен уды. Ишек төбендә Мәхмүд басып тора иде.

— Безнең белән киләчәктә тату яшим, дип ант итсәң, сине иленә җибәрәбез,— диде ул.

Кенәз шатлыгыннан сикереп торды.

— Ант! Ант!

— Башың өчен 200 мең сум бирерсең, ел саен ясак түләрсез. Безгә сез җимергән Казанны торгызасы бар.

— Баш өсте, баш өсте! — дип ачыргаланып кабатлады Василий.

Мәхмүд хан тәхеттә чагында, Казан өстенә һөҗүм итү турында мәскәүләр уйларга да курыктылар.

— **Имин йортта ил бәхетле булыр!** — дип шатланды Мәхмүд хан.

— Сүзең хак, олуг хан,— диде аңа Шәптәк морза.— Безнең халык сәүдә итәргә ярата. Борынгы Болгардагы Ага-базар кебек бер базар кирәк безгә.

— Җайлы урын бармы соң?

— Язгы сулар ярларына кайткач, Иделдә гаҗәеп бер атау ачыла. Шул — җайлы урын!

Сәүдә атавына һәр елның җәй башында Төркестаннан, Кавказдан, Себердән, Фарсыдан, Урыс иленнән йөзләгән сәүдәгәрләр килә башлады. Тирә-юнь шаулап торды. Берәү сата, берәү ала, берәү алдый, берәү алдана... Базар!

Казанга мал керә, Казан байый. Имин шәһәргә Алтын Урданың бөтен шәһәрләреннән татарлар агыла. Алар Мәхмүд ханның нык канаты астында яшәргә телиләр.

* * *

Дивар корыйк, диде Мәхмүд.
Салды нигезгә ташын.
Билдә һәрчак балта булсын,
Дошман икән юлдашың...

## Ибраһим хан

(?—1479)

Агасы Мәхмүд ханның үлүен ишеткәч, Касыйм Мәскәүгә ашыкты. Рәзән җирендә аның үз биләмәсе бар һәм аны Касыйм ханлыгы дип атыйлар иде.

— Казан тәхете миңа тиеш! — диде Касыйм.

— Анда хәзер Мәхмүд ханның улы Ибраһим утыра.— Мәскәү кенәзе Иван, сынап, Касыймга карады.

— Гаскәр бир, мин Ибраһимны пыран-заран китерәм!

Иван бераз уйланып торды. Татар белән татар сугышса, Мәскәүгә файда!

— Аннары минем сүздән чыкмассыңмы соң?

Казан тәхетенә менгерсәләр, Касыйм Иблискә дә буйсынырга әзер иде. Ул, урыс гаскәрен ияртеп, Казанга юнәлде.

Бу вакытта Ибраһим яшь хатыны Нурсолтан белән юана иде.

— Агаң Касыйм Казанга урыс явы белән килә! — дип, ханга хәбәр җиткерделәр.

Ибраһим тынычлыкта яшәргә ярата иде. Тик капкаңны дошман какса, ничек өйдә тыныч кына ятасың?

Казан гаскәрен күргәч, дошман Иделне кичәргә курыкты, кире борылды. Кайтышлый алар чирмешләр яши торган җирләрдә бик күп авылларны яндырдылар, хатын-кызларны, бала-чагаларны әсир алдылар.

Ибраһим ханның моңа бик нык ачуы килде. Бөтен гаскәрен җыеп, урыс өстенә китте. Гаскәренең бер өлеше коры җирдән

барды, икенче өлеше көймәләрдә Идел буйлап күтәрелде.

Татарлар өчен дә, урыслар өчен дә су өстендә бу беренче сугыш иде. Менә Ибраһим ханның корабы урыс көймәләре арасына барып керде. Идел өстенә ук яңгыры яуды. Урыслар көймәдән көймәгә сикереп кача башладылар. Ярацлау кенәзе генә җиңелергә теләмәде, күкрәгенә ук кадалгач та: «Каза-ан»,— дип ыңгырашты.

Аларны бай Казан кызыктыра иде.

Дошманны җиңсә дә, Ибраһим хан Мәскәү кенәзенә илчеләр җибәрде. «Тыныч яшик,— диде ул.— Мин үз җиремдә ханлык итәм, син үз җиреңдә. **Һәр халыкның үз җире»**.

Иван килеште. Үзе: «Киләчәктә күз күрер әле»,— дип уйлады.

Яудан кайткач, Ибраһим сырхаулады. Эргәсенә хатыны Нурсолтанны чакырды...

— Хәлем авыр, эчем яна... Казанны саклагыз...— диде хан.

— Күз карасыдай саклarбыз,— дип, Нурсолтан елап җибәрде.

* * *

Көймә эзлим яр буенда,
Шадра-шадра Идел өсте.
Юаныч өстәп, көймәдә
Ибраһим хан үтәр төсле.

## Нурсолтан

(якынча 1440—1519)

Ибраһим хан үлгәннән соң, ике ел үтте. Нурсолтанның кайгысы басыла төште, күзендә яше кипте. Ләкин ул һәр җомгада мәрхүм иренең төрбәсе янында намаз укый, андагы мөҗавирләргә (ханнар рухына дога укучылар) садака өләшә.

Беркөнне аның янына бер казак йөгереп килде.

— Кырымнан илчеләр килгән, ханбикәм,— диде ул.— Сине күрергә телиләр.

Менә бер ак сакаллы карт Нурсолтанның хөҗрәсенә керде. Дога кылдылар.

— Мин Кырым ханы Миңле Гәрәйдән яучы булып килдем,— диде мулла.— Ибраһим аның агасы иде, борынгы татар гадәте буенча, ул сине хатынлыкка сорый.

Нурсолтан күз яшьләрен сөртте. Ул монда көндәше Фатыйма ханбикә белән тыныша алмый иде. Ике улыннан башка бер таянычы юк. Тик уллары әле бик яшьләр шул.

Нурсолтан риза булды.

Яучы чыгып киткәч, төпчек улы Габделлатыйф йөгереп керде.

— Әни, без каядыр китәбез мәллә?

— Кырымга...

Малай шатланып көлеп җибәрде. Кырым турында ишеткәне бар иде аның. Менә, ичмаса, туйганчы йөзем ашар!

Ә олы улы Мөхәммәд Әмин Мәскәүгә, кенәз сараена китте. Нурсолтан Иванны үзенең дусты дип саный иде.

Җиде ел үткәч, Кырымга хәбәр килде: Мөхәммәд Әмин, Мәскәү кенәзе ярдәме белән, Казан тәхетенә утырган.

Нурсолтан йомшак күңелле, гүзәл табигатьле хатын иде. Мәскәүнең Кырым белән дә, Казан белән дә тату яшәвенә сөенде. Шул сөенечен хат аша Иванга да җиткерде.

Тик Мөхәммәд Әмин Мәскәү кенәзенең боерыгын үтәп туйган иде. Хан сараендагы илче бояр да аны күзәтеп, һәр адымын тикшереп тора.

— Мин бәйсез хан! — диде Мөхәммәд Әмин. Ул Казаннан Мәскәү шымчыларын куып җибәрде.

Иван Казанга сугыш белән янады.

Моны ишетеп, Нурсолтан Мәскәүгә ашыкты, аннары Казанга китте. Әйтерсең бу бөек Ана ике яу арасына ак яулыгын ташлады. Иван да, Мөхәммәд Әмин дә тынычландылар.

**Илнең иминлеге — аналарның самимилегендә**...

Нурсолтан Мәскәү кенәзенә иярләнгән ат бүләк итте. Ул бу атка атланып Мәккәгә хаҗга барган иде.

Мәскәүдә бүләк биргәнне яраталар.

* * *

Ыргылалар ирләр алга,
Калаларны ялкын ялмый.
Нурсолтанның ак яулыгы
Күктә инде... төшә алмый.

# Мөхәммәд Әмин хан

(1469—1518)

Мөхәммәд Әмин Болактан кирмәнгә күтәрелде. Кәефе әйбәт иде аның... Йөзләгән кеше Болакны чистартып, төбенә имән такталар җәя. Су хәзер үтәли күренәчәк. Балыкларның талгын гына йөзгәнен карап, хыялланып утырырга ярата иде хан.

Сарайга кергәнче, ул һөнәрчеләр йортына кереп чыкты. Анда ал-

тынчылар, көмешчеләр эшли. Кайсысы савыт-саба, кайсысы йөзек-беләзек ясый. Хан түргәрәк узды. Анда бер оста казгана. Бер мәлгә Мөхәммәд Әминнең күзләре камашып китте. Аңа дигән бүрек иде бу, ә асылташлары ничек җемелди. Татар таҗы! Һәр асылташ данлы бабаларын искә төшерә сыман...

Хан сарайга ашыкты. Әле аның Сәмәркандтан Шәйбән хан җибәргән көйчеләрне, думбырачыларны, сазчыларны, җыручыларны күрәсе бар. Голәм Шади исемлесе бигрәк тә моңлы җырлый, имеш.

Шул чагында аңа Мәскәү кенәзенең илчесе Кляпик очрады. Ул әле Казанга күптән түгел генә килгән иде.

Ханны күргәч, ул мыскыллы елмайды:

— Кирмән диварын ныгытырга боергансың икән, хан,— диде ул.— Бөек кенәз Иван ни әйтер?..

— Мин аңа хәбәр итәрмен,— дип, Мөхәммәд Әмин алга атлады.

Хатыны Фатыйма аны күптән көтә иде.

— Син бу хәлгә ничек түзәсең? — дип каршы алды ул.— Без үз йортыбызда тоткыннар кебек яшибез. Һәр адымны урыс күзәтеп тора. Син ханмы, әллә кенәз колымы?

Ләкин Мөхәммәд Әмин бик сак, хәйләкәр кеше иде.

— Сабыр ит! — диде ул.

Үзе шигырь язарга утырды.

Икенче көнне бөтен Казан халкы кубып, ятларны үз илләренә куды.

**Саклык белән дә илне саклап була**.

Халык тантана итте.

Хан бераздан урыс гаскәренең Казанга килүен ишетте. Шунда ук үзенең карачысын чакырды, Арча кырына мең чатыр корырга, аларга күп ризык, исерткеч эчемлекләр куярга кушты.

Казанга якынлашкан йөз меңлек урыс гаскәре, чатырларны күргәч, шунда ташланды. Андагы ризыкны, эчемлекләрне татыгач, Казанга һөҗүм онытылды.

Мәскәү бәйрәм ярата.

Икенче көнне исереп беткән хәсрәт сугышчылар өстенә Казан гаскәре бөркет булып ыргылды.

* * *

Мөхәммәд Әмин җыр ишетте:

Һай, моңлы көенең агышы.

Сагышлы курайга кушылды
Укларның сызгырган тавышы.

## Мөхәммәдьяр

(якынча 1497 ел — XVI гасыр уртасы)

Үтәмеш Гәрәйне хан итеп күтәргәч, Сөембикә, шул хәбәрне ирештерер өчен, Мәскәүгә илчеләр җибәргән иде. Мөхәммәдьярны тылмач итеп билгеләделәр.  Ул урыс телен әйбәт белә иде. Инде менә ничә ай Мөхәммәдьяр Мәскәү төрмәсендә ята.

Үтәмеш Гәрәйнең тәхеткә менүен, Сөембикәнең ханлык итүен ишеткәч, Мәскәү кенәзе Иван ачуыннан кара көйде.

— Илчеләрне төрмәгә! — дип акырды ул.

Мөхәммәдьяр, үзенең бер шигырен искә төшереп, елмаеп куйды. «Көфер белән мәмләкәт булмас харап, Золым белән егылыр олыс йөдәп»,— дип язган иде ул. Ягъни кяферләр үзләре генә аның илен җиңә алмас, аларга үз  сатлык татарыбыз булышса гына, ил егылыр, харап булыр. Тәкәббер Казан морзаларын аз күрдемени ул?! Һәрберсе үз кесәсен кайгырта, үзе баеп калырга ашыга, ил кайгысы гамьнәрендә дә юк! Дошман җиңсә, ул байлыкларыннан туфрак, көл өеме генә каласын уйларына да китермиләр. Шуларга бераз аң кермәсме, дип язды ул шигырьләрен.

Менә хәзер үзе кяфер төрмәсендә ята.

**Илне имин тотар өчен көчле хан кирәк**. Сәхиб Гәрәй хан кебек... Кырымда әнә ул бөтен тирә-яктагы дала татарларын үзенә җыя икән. Гаделлек белән ханлык итә. Мәчет-мәдрәсәләр салдыра...

Җиде-сигез еллар элек Мөхәммәдьяр аңа багышлап кыйсса да язды. Хәзер шундагы  сүзләр исенә төште: «Олуг солтан бөек Сәхиб Гәрәй хан... Падишаһтыр, җир йөзендә исме бар, Дәүләт, муллык иясе, бәхтияр...»

Кыйссаны алгач, Сәхиб Гәрәй аңа бик күп бүләкләр җибәрде.

Шагыйрьләр сүзенә колак сала торган ханнар сирәк була...

Мөхәммәдьярның зинданда ятуына Сөембикә дә бик көенде. Әтисенә — Нугай Урдасының бие Йосыфка хәбәр салды. Алар бит Иван белән дус булып кыланалар. Әтисе үтенсә, бәлки кенәз шагыйрьне азат итәр?

Йосыф бинең үтенеч хатын укыгач, Иван мыскыллы көлде. Мөхәммәдьяр төрмәдә чирләп үлде, дип җавап язарга кушты.

Берничә көннән төрмә ишеге шыгырдап ачылды. Бусагада айбалта күтәргән алып гәүдәле кеше пәйда булды.

Мөхәммәдьяр дөньяга атлады.

* * *

Шагыйрьләрнең каберләрен эзлим,—
Кай тирәдә икән Мөхәммәдьяр?
Соңгы сүзен ишетәсе иде...
Дөрләп янган безгә дигән хатлар.

## Сәхиб Гәрәй хан

(якынча 1500—1551)

Кырымга Казаннан илчеләр килә.

— Мөхәммәд Әмин үлгәннән соң, безне тәмам урыс басты,— диләр алар.— Касыймнан Шаһгалине хан итеп китергәннәр иде, ул мәскәүләрнең сүзеннән башка берни кыла алмый. Коткар безне, олуг хан! — дип, Кырым ханы Мөхәммәд Гәрәйгә мөрәҗәгать итәләр.— Энең Сәхиб Гәрәйне безгә җибәр. Казан тәхете — аныкы!

— Хуп! — диде Кырым ханы.— Сезнеңчә булыр.

Сәхиб Гәрәй Казанга китәр алдыннан, абыйсы аны үз янына чакырды.

— Казан тәхетенә менүгә, гаскәр җыеп, Мәскәүгә һөҗүм ит, мин дә яуга кузгалам. Коломна шәһәрендә очрашырбыз.

Шулай сүз берләшеп, ике бертуган кочаклашып аерылышты.

Сәхиб Гәрәй 300 җайдагы белән Казан диварына якынлашты. Хан капкасы ачык иде.

Мәскәү ялчысы Шаһгали шәһәрдән чыгып качкан.

Халык шаулый, көлә, шатлана, алкышлый — тулган ай йөзле, киң җилкәле Сәхиб Гәрәй ак атта Хан сараена бара.

— Тиздән Мәскәүдән яу киләчәк,— диде яңа хан.— Шуңа алардан уздырып үзебез һөҗүм итик!

**Ханы каһарман булса, халыкның да каны кузгала**.

Кырым гаскәре белән Казан гаскәре, берләшеп, Мәскәү капкасына килеп җиттеләр.

Мәскәү кенәзе, гадәттәгечә, гаскәр җыям дигән булып, шәһәрдән чыгып качкан иде.

Шәһәр халкы, аңгыраеп, анда чапты, монда чапты, ахырдан Казан ханы белән Кырым ханына зур бүләкләр җибәреп, кичерү сорады. Василий кенәз дә һәр ел саен ханнарга ясак түләргә шатланып риза булды. «Киләчәктә күз күрер әле»,— дип уйлады

ул.

Ике гаскәр дә өйләренә кузгалды.

Мәскәүнең Казанны тынычлыкта калдырмаячагын Сәхиб Гәрәй беләидe, шуңа, ярдәм сорап, Истанбул-

га — төрек солтаны янына китте. Казан тәхетендә үзе урынына энесе Сафа Гәрәйне калдырды.

Ләкин Казанга кире кайтмады. Аны Кырым тәхетенә күтәрделәр.

Кырымда да ул Казанга гел ярдәм итәргә тырышты. Шуңа күрә Казан шагыйре Мөхәммәдьяр аны мактап поэма язды...

* * *

Калды Казан. Карлы Казан.
Монда — Кырым. Диңгез шаша...
Тыңлап ята Сәхиб Гәрәй:
Кем эндәшә? Ыңгыраша?

## Сафа Гәрәй хан

(якынча 1510—1549)

Мәскәү кенәзе Шаһгалине сараена чакырды.

— Гәрәйләр синең тәхетеңне тартып алды. Сәхиб Гәрәй Истанбулга киткәннән соң, хәзер анда ундүрт яшьлек Сафа утыра. Тартып ал Казан тәхетен ул малайдан!

Шаһгали, сөенә-сөенә, урыс гаскәре белән Казанны алырга китте. Иделдәге сәүдәгәрләр атавына төшкәч, ул Сафа Гәрәйгә хат юллады: «Яхшылык белән Кырымга кит, тәхет — минеке!»

Сафа Гәрәй каушап калмады. «Тәхет җиңүченеке булыр!» — дип җавап бирде.

Сугыш башланды. Казанны саклаучылар нык торды. Чуашлар, чирмешләр дошманның артына төшеп сугышты.

Дошман, җиңелеп, үз иленә кайтып китте.

Ләкин Сафа Гәрәй аларның тагын киләсен белә иде. Мәскәү кенәзе Казанны җимермичә тынычланмас. Казан иленең уңдырышлы җиренә кызыга ул. Тик җир уңдырышлы булсын өчен, анда маңгай тирен агызып эшләргә кирәк.

**Кылыч белән җир сөреп булмый**.

Казанны саклар өчен көчле гаскәр кирәк. Сафа Гәрәй Кырымнан, Нугай Урдасыннан үз янына батыр яугирләр чакырды.

Казан морзаларының моңа ачуы килә иде.

— Ул һаман Кырым кешеләрен үз янына җыя, алар тиздән

безнең башка менеп утырачак! — дип, Тагай би беркөнне үз ишләрен киңәшкә дәште.

— Мәскәү кенәзенә хат язарга кирәк, безгә хан итеп Шаһгалине җибәрсен,— диде мәрхүм Мөхәммәд Әминнең сеңлесе Гәүһәршад.

Казан морзаларының үзенә каршы икәнен белгәч, Сафа Гәрәй Кырымга китте. Аннан зур гаскәр алып, Мәскәү өстенә барды. Василий кенәзгә хат язды: «Казанда хан булган чагымда һичкайчан синең җиреңә кермәдем, ә син һаман безнең илгә һөҗүм иттең. Казан сатлыкларын котыртып, мине тәхеттән кудырдың. Менә хәзер шуның җәзасын ал!»

Ә Казанда халык кайный иде: «Казанның азатлыгын саклар өчен безгә Сафа Гәрәй кирәк!»

Сафа Гәрәй Казанга кайтты, Мәскәү яклылар, хыянәтчеләр кенәз янына качтылар.

* * *

Кылыч тартты тагын Сафа Гәрәй,—
Татар өметенең актыгы...
Иң зур дошман урыс түгел, диде.
Иң зур дошман — татар сатлыгы.

## Сөембикә

(1519—1557)

Сафа Гәрәй йокыдан кәефсез торды. Хатыны Сөембикәне күргәч кенә, йөзенә елмаю йөгерде.

Сөембикә комганга су салды.

— Кил, юын, солтаным! — диде.

Сафа Гәрәй аңа таба ике адым атлады да, кылыч кискән кебек, идәнгә ауды.

Сөембикә ачыргаланып кычкырды. «Дошманнар агулаган!» — дигән уй башыннан үтте.

Сафа Гәрәй үлгәч, дошманнар куанды. «Безнең көн килде!» — дип кычкырды алар.

Сөембикә Казанның олы кешеләрен сарайга җыйды. Янында хан гаскәренең башлыгы Кошчак оглан басып тора иде.

— Тәхеткә бүген Сафаның улы Үтәмеш утыра! — диде Сөембикә.

— Ул әле сабый гына бит,— диде Ходайкол оглан.

— Үтәмеш үсеп җиткәнче, миңа буйсынырсыз! — Сөембикәнең

карашы кырыс иде.

Шушы хәбәрне җиткерергә Мәскәүгә илчеләр китте. Аларның җитәкчесе Бакшанда морза иде.

— Сафа Гәрәй үлде, хәзер Казан иленең башлыгы — Сөембикә,— диде ул.

— Көнегез хатын-кызга калдымы? — дип көлде Мәскәү кенәзе Иван. Ул үзен хәзер патша дип атый иде.— Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска.

— Сөембикә акыллы хатын,— диде илче.

— Борынгы татар гадәте буенча, тол калган ханбикә үлгән ханның туганына кияүгә чыгарга тиеш. Сез аны монда, Шаһгалигә тотып җибәрегез.

— Казанда Шаһгалинең туганы юк! — диде Бакшанданың тылмачы Мөхәммәдьяр.

— Илчеләрне төрмәгә! — дип акырды Иван.

Бу хәбәрне ишеткәч, Сөембикә Казаннан Мәскәү кешеләрен куарга боерды.

— Без Сафа вакытындагы кебек үк көчле булырга тиеш! — диде ул.— Дошман безне куркыта алмас!

Бераздан Мәскәү гаскәре Казан өстенә килде.

— Сөембикәне минем кулга бирсәгез, Казанга һөҗүм итмим,— диде Иван.

— Урыс көчле, без аңарга Сөембикәне биреп котылыйк,— дип, морзалар бер-берсе белән сөйләште.

**Бәхетсез илнең тәхетенә еланнар үрмәли**.

Алар Сөембикәне урысларга бирделәр. Казан өстендә бичара ханбикәнең сыктау авазы яңгырады: «Кызганыч син, канлы, кайгылы шәһәр! Синең башыңнан таҗың төште...»

Халык Сөембикәне елап озатты. Соңыннан бәет чыгардылар...

* * *

Сөембикә! Сиңа дәшәм,
Бәгырькәем сызганда...
Үз баласын сөрә татар,
Аннан елап кызгана.

## Япанчы

(?—1552)

20 августта урыс гаскәре Иделне кичте. 150 мең кешелек гаскәр

Хан болынына аяк басты. Татар җирен чебен кебек сырып алган бу чирүне туктатырлык көч дөньяда юк иде кебек.

— Аллага гына өмет баглыйбыз,— диде Кол Шәриф. Аның янына Казан олуглары — Чапкын, Зәйнәш, Ислам, Галикәй, Кәбәк, Дәрвиш бәкләр җыелган иде. Алар, манарага менеп, дошман ягына карадылар. Хан болынының уртасына урыслар зур тәре утыртып куйганнар, инде чиркәү сала башлаганнар иде.

Кол Шәриф Япанчы бәкне чакырды. Бу — күп сугышларда чыныккан курку белмәс яугир иде.

— Дошман Казанны тиздән чолгап алыр,— диде Кол Шәриф.— Син гаскәрең белән хәзер Биектауга кит. Анда сиңа Арча бәге Яуш кушылыр. Бергә-бергә дошманның артына төшеп һөҗүм итәрсез.

Япанчы атка менде.

Бераздан туплар ата башлады, Мәскәү гаскәре Казан диварларына таба кузгалды. Алар иң алдан әсир татарларны кудылар. Казанны саклаучылар үз кешеләренә атмас, янәсе. Әсирләр: «Казанны бирмәгез, атыгыз! Безне кызганмагыз»,— дип кычкырдылар.

Казан диварларыннан ук яңгыры яуды, туплар гөрселдәде.

Урыслар инде Хан капкасына килеп җиттеләр. «Җиңәбез!» — дип кычкырды Иван.

Тик ни бу? Урман эченнән Арча кырына җайдаклар бәреп керде, алар каушап калган дошманны кыра башлады.

Ачуы бугазына кысылган Иван воеводаларына ысылдады:

— Кемнәр ул?

— Япанчы!

Иң алда чем кара атына атланып, үлем хәбәрчесе кебек, Япанчы җилдерә иде. «У-ра-а!» — дип кычкыра үзе.

**Илне күтәрергә кайчакта бер аваз җитә**.

Урыслар аңга килгәнче, алар урманга кереп юк та булдылар.

Казанга һөҗүм тагын кичекте.

— Япанчыны юк итмәс борын, без Казанны җимерә алмыйбыз! — диде Иван.

Мәскәү гаскәре Арча ягына ыргылды.

Япанчы гаскәре соңгы кешесенә кадәр сугышты. Иң соңыннан урыслар чем кара атны күрделәр. Иярдә җайдагы юк иде. Ат ялларын җилдә таратып төнгә кушылды.

* * *

Инде кулдан кылыч төшкәч,
Ат, дип, ятып калганчы,
Көтмәстән дошман өстенә
Ябырылыр Япанчы.

# Кол Шәриф

(?—1552)

Борын-борын заманда татарларның үз дәүләте — беркемгә дә буйсынмаган бәйсез Казан ханлыгы булган. Казанга якынлашкан һәр сәяхәтче мондагы исәпсез-сансыз биек, төз мәчет манараларын күреп сокланган. Ләкин иң гаҗәпкә калдырганы: Хан сараена якын гына салынган Җәмигъ мәчет икән. Аның сигез манарасы гүя Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатен Казан җиренә иңдереп торган.

Монда дәүләтнең дин башлыгы үзе хөтбә укыган. Һәр хөтбәсендә илнең бәйсезлеген якларга чакырган. Дин башлыгын сәед дип атаганнар. Сәед — Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган.

Урыс явы янә Казан диварлары төбенә килеп җиткәндә, дәүләтнең дин башлыгы Кол Шәриф сәед Хан сараена юнәлгән. Ул бик мәһабәт гәүдәле, акыллы, белемле кеше, өстәвенә мәшһүр шагыйрь дә икән.

— Иван патшадан Сезгә — гыйззәтле вә хөрмәтле сәедкә — хат килде,— дигән Ядегәр хан.— Ул безнең бирелүебезне таләп итә.

— **Күк ишелсә дә, Казан дошман кулына төшмәя-чәк!** — дип җавап биргән Кол Шәриф.— Кяфергә шулай дип язарбыз.

Әмма дошман гаскәре безнекеләрдән биш тапкырга артык булган. Тигезсез сугыш башланган. Кырык көн буена орышканнан соң, урыслар җир астыннан казып кереп, Казанның калын диварын шартлатканнар. Сөңгегә сөңге бәрелгән, кылычка — кылыч... Тик көчләр тигез булмаган шул, татар гаскәре кырылып беткән, урыслар арба кендегеннән биегрәк булган һәр ир-атны үтергәннәр, хатын-кызларны, сабыйларны әсир итеп Мәскәүгә алып киткәннәр.

Дошман мәчет янына килеп җиткәч, аннан чалма-чапан кигән Кол Шәриф килеп чыккан. Тирә-ягында шәкертләре икән...

— Динебез, илебез өчен шәһит китәбез! — дип кычкырган Кол Шәриф һәм кыныннан кылычын суырып яуга ташланган.

Алар барысы да кырылып беткән. Баһадир Кол Шәриф сәед тә, урыс угы тиеп, туган туфрагына ауган.

Ул көннәрдән соң инде күп заманнар үтте, тик Кол Шәриф

шигырьләре Казанның аулак төннәрендә гүя җил булып искәндәй безгә эндәшә әле:

И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр...

Ә таң алдыннан олуг сәед, үз мәчетенең мөнбәренә менеп, янәдән соңгы хөтбәсен сөйләр төсле...

* * *
Безгә тагын соңгы тапкыр
Сират күпере үтәсе.
Ишетелми ләкин никтер
Кол Шәрифнең хөтбәсе.

## Мәмеш-Бирде

(?—1556)

Урыслар Казанны басып алгач, аларның патшасы Явыз Иван боерык биргән:

— Хатын-кызларны, чукындырып, Мәскәүгә әсирлеккә куыгыз, ә арба күчәреннән дә биегрәк ир-атларны кылычтан үткәрегез!

Ләкин исән калучылар илбасарларга каршы әледән-әле баш күтәреп торган. Аларның юлбашчысы Мәмеш-Бирде дигән Казан морзасы икән, урыслар Казанны алгач, ул, үзенең гаярь яугирләре белән чолганышны өзеп, кара урманнарга кереп югалган. Бик күп җәфа күргәннән соң, алар Идел ярына килеп чыкканнар. Анда Сөндер тавы өстендә кечкенә генә Чалым каласы бар икән. Мәмеш-Бирде үз яугирләре белән шунда күтәрелгән. Кала кешеләре аны сөенеп каршы алганнар. «Бу безне урыслардан саклый алыр»,— дип уйлаганнар.

Мәмеш-Бирде җимерелгән, яндырылган Казан ягына караган, керфегендә җемелдәгән күз яшьләрен сөрткән. **Батыр егеткә еларга ярамый!**

— Безнең халык беркайчан да дошманга буйсынмас,— дигән ул үз тирәсенә җыелган кешеләргә.— Изге сугышка әзерләнегез! Азатлык килер...

Чалым каласы урыслар басып алган татар иленең яңа башкаласына әверелгән. Килмешәк илбасарларга каршы аяусыз көрәш башланган.

Дошманга дүрт ел каршы торган Мәмеш-Бирде! Әмма беркөнне аңа кул астындагы чуашлар хыянәт иткәннәр. Йокыга китүен көтеп

торганнар да, кул-аякларын бәйләп, урысларга илтеп тапшырганнар. Шатланышкан илбасарлар тиз генә татар батырын Мәскәүгә алып киткәннәр һәм, чиркәү чаңнары кага-кага, Кызыл мәйданда башын чапканнар.

Хәзер дә Сөндер тавына Идел дулкыннары бәреләә. Алар курку белмәс Мәмеш-Бирде батырны сагыналар һәм, безне йокыдан уятырга теләп, «Азатлык!» дип пышылдыйлар төсле.

* * *

Кызыл мәйданда йөриләр,
Меңнәр килеп табына.
Кызыллаткан аны юкса
Мәмеш-Бирде каны да...

## Гали-Әкрәм

(?—1556)

Сөембикә ханбикәне урыслар, аяк-кулларын бәйләп, Мәскәүгә алып киткәч, аның Нугай илендә калган Гали-Әкрәм энесе, атына атланып, далага чыгып чапкан. Ул апасын рәнҗетүчеләрдән үч алырга ант иткән.

Менә беркөнне аны эзләп, тирмәсенә берничә кеше килеп кергән.

— Казанны урыслар басып алды,— дигәннәр алар.— Хатын-кызларны чукындырып, Мәскәүгә әсирлеккә кудылар, арба күчәреннән дә биегрәк ир-атларны кылычтан үткәрделәр, ә ханыбыз Ядегәрне, тимер читлеккә ябып, Мәскәүгә алып киттеләр.

— Аллага шөкер,— дип дәвам иткәннәр бу илчеләр,— бездә курку белмәс батырлар күп әле. Каһарман Мәмеш-Бирде халыкны явыз илбасарларга каршы көрәшкә күтәрде. Чалым шәһәрен башкала итте. Яңа башкалага яңа хан кирәк, Галим-Әкрәм. Хан бул безгә, Сөембикә апаң өчен урыслардан үч ал!

Илчеләр шулай диеп Гали-Әкрәмгә алтынланган көбә, тимер башлык, көмеш саплы кылыч сузганнар.

Үзенең яугирләре белән Чалымга килгән Гали-Әкрәмне хан итеп күтәргәннәр. Яңа хан үз халкына каланы ныгытырга, илбасарларга каршы изге сугышка әзерләнергә кушкан.

Гали-Әкрәм үзен нинди язмыш көткәнен яхшы белгән, әлбәттә. Дошман көчле, мәкерле. Татарлар аз, таркау... Тик барыбер соңгы батыр егылганчы орышырга кирәк! **Яуда үлү — җиңелү түгел**...

— Тамырын корытырга! — дип җикеренгән Мәскәүдә урыс

патшасы Явыз Иван.— Татарлар мәңге кулларына кылыч алмаслык булсын.

Тик Гали-Әкрәм дә, Мәмеш-Бирде дә, аларның яугирләре дә курку белмәс батырлар икән! Алар дүрт ел буе үзләреннән көчлерәк дошманга каршы сугышканнар.

Соңгы сугышта татар иленең соңгы ханы Гали-Әкрәм акрын гына аттан егылган — аның арган кайнар йөрәгенә урыс угы килеп кадалган. Ханның каны тамган урында кызыл чәчәкләр үсеп чыккан. Алардан азатлык исе, батырлык исе килә!

* * *

Хан тәхете — ияр аңа.
Гали-Әкрәм, сабак бир!
Илеңне дошман яуласа,
Һәркем хан, һәркем яугир.

## Җангали батыр

(?—1616)

Казан ханлыгын басып алгач, урыслар татарларны үз җирләреннән куалар, авылларын яндыралар, каршылык күрсәтүчеләрне үтерәләр, хатыннарын, балаларын әсир итеп, Мәскәүгә алып китәләр.

Урыс изүеннән качкан татарлар кара урманнарга, сазлыкларга барып урнаша, яңа авылларга нигез сала. Тик илбасарлар аларны барыбер тынычлыкта калдырмый. Чөнки урыслар бу вакытта литва, поляк дәүләтләре белән сугыша, урыс гаскәренә кыю, көчле татар егетләре, ә корал ясар өчен күп акча кирәк була. Игенчеләргә, һөнәрчеләргә түләп булмаслык салымнар салына.

Татарларның сабырлыгы сына. Алар Җангали батыр янына киләләр. Ул инде элегрәк тә кан кардәшләрен илбасарларга каршы күтәргән була.

— Урыслар безнең азат илебезне басып алдылар, илсез-җирсез калдык, инде алар безне кол итәргә тели... Кардәшләрем, коралланыгыз! — ди ул.

Баһадирлар кол булып яшәгәнче, һәрвакытта да үлемне артыграк күрәләр.

Изелгән, куылган татарларның инде җүнле кораллары да булмый. Алар сәнәккә, балтага тотына. Шулай да Җангали үзенең көрәштәшләре белән илбасарларның мең кешелек гаскәрен тар-мар

итә.

Тик көчләр тигез булмый. Җангали үзенең кешеләрен Истанбулга — төрек солтанына җибәрә.

«Кяферләр безне кешелектән чыгарды. Без илебез, динебез өчен көрәшкә күтәрелдек. Ләкин дошман көчле. Ярдәм ит безгә, бөек солтан!» — дип яза ул үзенең хатында.

Әмма Төркия — ерак, дошман — туган җирдә... Урыс патшасының Казандагы вәкиле Долгорукий кенәз (татарча: Озын кул) баш күтәрүчеләр өстенә исәпсез гаскәр җибәрә.

Инде Казан тирәләрен дошманнан азат иткән татарлар аяусыз сугышка керә.

**Башны куяр өчен дә туган җир кирәк!**

«Татарларны һәм мариларны бихисап кырдылар, кайберләрен әсир алдылар»,— дип яза елъязмачы.

Җангали үзе дә әсирлеккә эләгә. Аны иң якын көрәштәшләре белән бергә Казанда җәзалап үтерәләр.

1616 ел...

Изелгән, йончыган, канга баткан татар иле күп елларга тынлыкка чума. Тик, Алла шаһит, үлем тынлыгы булмый бу. Татар, тешен кысып, күз яшен йотып, яңа көрәшләргә хәл җыя.

* * *

Җангали юк арабызда:
Кылыч, сөңге безгә яттыр.
Ләкин һаман кабатлана:
Соңгы тапкыр... соңгы тапкыр...

## Мәүла Колый

(XVII гасырның икенче яртысы)

Шәһре Болгар өстенә караңгылык төште. Якында гына Олы манара, Кече манара кучкылланып күренә. Мәчет хәрабәсе янында борынгы кабер ташлары ята.

Бер читтәрәк торган дәрвишләр ханәкасенең (суфилар, дәрвишләр торган урын) тәннегеннән генә сүрән яктылык саркыла. Илбасарлар туздырган татар иленең укымышлы галимнәре, шагыйрьләре, дәрвишләре җыела анда... Шәех Мәүла Колыйның шигырьләрен — гыйбрәтле хикмәтләрен тыңлыйлар да тагын авылларга таралалар: сабыйларга белем бирәләр, олыларга дин гыйлемен, шәригать кануннарын өйрәтәләр.

Бу ханәкане Мәүла Колыйның остазы Мелла Мамай салдырган. Мамай үзе Казанда мәктәп-мәдрәсә тоткан атаклы галим иде.

— Син Болгарда изге әрвахлар рухына дога кылып, халыкка хикмәтләреңне чәч...— диде ул яраткан шәкертенә.

Инде ничә ел Мәүла Колый  Болгар хәрабәләре арасында яши. Гүя ул элекке олуглык белән бүгенге мескенлек арасына күпер булып сузыла.

Менә бер читтәрәк утырган дәрвиш торып басты.

— Тәкъсир! — дип остазына эндәште ул.— Халык бозылды. Динебезне онытып, үзара мал өчен ызгыша. Бүгенге рәхәтлекләр хакына теге дөнья газапларын оныта.

Мәүла Колый, тамагын кырып, яңа хикмәтен әйтә башлады:

Дөнья өчен талашканнар — этләрдер, бел,
Талашканнар китәр, дөнья калыр, күргел.

Кинәт ишек ачылды да, өтек кенә киенгән бер кеше килеп керде. Карт караманың тамырлары кебек коргаксыган кулларын күкрәгенә куеп баш иде. Кунаклар аңа яратмыйча карадылар. Бу кара сөяк монда нишләп йөри, янәсе...

Ә ул, Болгарда зур галим яшәгәнен ишетеп, зарын сөйләргә, юаныч алырга килгән иде. Аның җире аз, уңышсыз, ә салымнар күп... Инде балалары ачыга башлады.

Мәүла Колый, урыныннан торып, игенчене хөрмәт белән каршы алды:

Игенченең кул-аягы булыр туфрак...
Хак Тәгалә каршысында йөзләре ак!

**Шагыйрь — бичара халыкны юатучы...**

Берничә көннән Мәүлә Колыйның әлеге хикмәтләре, телдән телгә күчеп, бөтен татар иленә мәгълүм булды.

* * *

Инде ил таралган, дисәң,
Бәйләр җепләр өзелгән...
Пәйда була  Мәүла Колый,
Укмаштыра сүз белән.

Хәсән Карачура

(XVII гасыр ахыры)

Урыс дәүләте көннән-көн киңәя бара. Патшага, аның янына елышкан боярларга һаман җир җитми. Алар зур гаскәр белән һаман күрше җирләргә яу чабалар. Артта яндырылган шәһәр-авыллар, сугышта башын салган яугирләр кала. Мәскәүгә таба богауланган әсирләр ыңгырашып атлый.

Тик сугышлар өчен бик күп байлык кирәк. Мәскәү патшасы үз халкын да кызганып тормый, урыс крәстияне бөтенләй ыштансыз кала.

Бу хәл казакларга бер дә ошамый. Алар борынгыдан ук ирекле яшәргә өйрәнгән, мондый талауга риза булмыйлар. Казаклар мәйданга җыела. Разин дигән атаман уртага үтә.

— Мин сезгә ирек бирергә килдем! — ди ул.

Аның янына татар морзасы Хәсән Карачура да килеп баса.

— Татарлар да синең белән, атаман! — ди Карачура.— Бергә булганда гына, канэчкеч Мәскәү патшасын бәреп төшерербез, үз илләребезгә үзебез хуҗа булырбыз.

Хәсән Карачура — белемле, акыллы, сүз остасы. Ул татарларны көрәшкә чакырып өндәмәләр яза, аларны авылларга юллый.

Казакларга меңләгән татар кушыла. Алар үз Ватаннары өчен изге көрәшкә күтәреләләр.

Хәлиткеч сугышта баш күтәрүчеләр җиңелә. Хәсән Карачура да дошман кулына төшә, аның җирләрен тартып алып урыс боярына бирәләр.

Ул үзе юк инде, кабере дә билгесез, тик аның замандашларына язган хатлары гасырлар аша безгә килеп җиткән, алар һаман азатлыкка чакыра. **Азатлыкны теләнеп, соранып түгел, яулап, даулап алалар!**

* * *

Карачура хатлар язды:
«Яуга чыгыйк ирек өчен!»
Мең кылычны күтәрерлек
Бер каләмнең дәһшәт көче...

# Теләкәй — Күчем — Акай — Габдулла

(XVII гасыр ахыры — XVIII гасырның беренче яртысы)

Петр патша, тәхеткә менгәч үк, дөньяны басып алу турында хыяллана башлый. Ул төрек җирләренә һөҗүм итә, шведларга каршы сугыш ача. Сугыш өчен корал кирәк. Петр патша халыкка күп салым сала, акча җыя. Ул бигрәк тә татарларны кызганмаска куша, алардан морҗадан чыккан төтен өчен дә, ясин укыган өчен дә, хәтта күзенең төсенә карап та акча таләп итә. Соры күзле татар — алты, ә кара күзлесе сигез тиен түләргә тиеш була.

Бу хурлыкка Тамьян олысының башлыгы Теләкәй батыр түзә алмый — тирә-якка чапкыннар җибәрә, барча татарны баш күтәрергә, илбасарлар белән сугышырга чакыра.

Мәскәүдән зур гаскәр килә, начар коралланган татарлар янә җиңелә. Аларның күбесен үтерәләр, хатыннарын, балаларын чукындырып Мәскәүгә куалар. Әсир төшкән Теләкәй батырны урыслар дарга аса.

Әтисенең кулыннан төшкән кылычны Теләкәйнең улы Күчем күтәреп ала һәм илбасарлардан үч алырга ант итә. Күчем батырның гаскәрләре башка көрәшчеләр белән бергә Казан янына ук килеп җитә. Күчем батыр, Алдар тархан, Исмәгыйль абыз, Уразай каһарман бергә җыела. Тик алар арасында бердәмлек булмый, Казанга һөҗүм һаман сузыла.

Ул арада Мәскәүдән урыс гаскәрләре якынлаша, татарлар Чулман елгасы аръягына чигенәләр. Илбасарлар татар авылларын талый, халкын Рәсәйнең яңа башкаласы Петербургны салырга куып алып китә. Бу сазлык җирдә бик күп кеше һәлак була.

Шулвакыт Күчем батырның улы Акай яраннарын үз җәйләвенә чакыра. «Без коллар түгел! — ди ул.— Безнең тамырларда затлы ханнар каны ага! Минем кулда — Теләкәй бабам кылычы! Яуга!»

**Затлы каннан асыл уллар туа.**

Үз җирләрен саклап калырга, үз дәүләтләрен торгызырга омтылган татарлар белән илбасар урыслар арасында биш елга сузылган канкойгыч сугыш башлана. Баш күтәрүчеләр соңгы тамчы каннарына кадәр сугышалар. Ләкин, аяныч, илбасарлар күп һәм яхшы коралланган була, алар азатлык яулап изге яуга кузгалган каһарманнарны тар-мар итәләр.

Яраланган Акай батыр әсир төшә... Әтисенең кулыннан төшкән кылычны үз кулына алган Габдулла Уфага берничә мәртәбә һөҗүм ясый, әтисен коткармакчы була. Бу вакытта инде Акайны зинданда асып үтергән булалар.

— Теләкәй! Күчем! Акай! Габдулла!

Алтмыш ел буена илбасарларга каршы туктаусыз баш күтәргән бу нәсел... Исемнәрен истә тотыйк.

* * *

Учактагы соңгы куздай
Сыңар өмет җанда кала:
Кулдан төшсә изге кылыч,
Туруннар күтәреп ала.

## Морат солтан

(?—1708)

Татар иленең азатлыгы өчен изге яуга күтәрелгән каһарманнар Казан ханлыгын яңадан төзергә хыялланалар. Аларга Чыңгыз нәселеннән чыккан хан кирәк була. Азатлык өчен яуга күтәрелүче юлбашчыларның берсе Алдар тархан Исәнгилде Күчем хан нәселеннән булган  Морат солтанны  хан тәхетенә чакыра.

Морат утызлап яраны белән төрек солтаны  Әхмәт хозурына, урыс илбасарларына каршы көрәштә ярдәм сорау өчен, сәфәргә кузгала.

Урыс илчеләре, төрекләр белән Кырым татарлары Мәскәүгә һөҗүм итмәсен өчен, Әхмәт солтанның вәзирләренә бүләк рәвешендә акча өләшәләр. Солтанны сугыш ачмаска үгетләү өчен, урыс илчесе  миллион ярым алтын сарыф итә. Озын юл үткән Морат солтан бернинди ярдәм ала алмый.

— **Татарга татардан башка ярдәм итүче булмас!** — ди Килмәк Нарыш. Ул соңрак яуга күтәрелгән татарларның атаклы юлбашчысы булачак әле.

Кире кайтканда, Морат солтан Кубанда туктый. Андагы татарлар аны чын хан итеп таный. Аларга нугай, кумык, чәчән һәм башка халыклар да иярә. Меңнән артык гаскәре белән Морат солтан Терек каласын ала. Аның исемен ишеткәч, илбасарлар дер калтырап торалар. Тик Әстерханга башлык итеп куелган кенәз Апраксин гаять зур гаскәре белән азатлык өчен көрәшүчеләрне тар-мар итә.

Морат солтанны 1708 елда әсирлеккә алалар. Ул илбасарлардан рәхим-шәфкать көтми, горур килеш кала. Ханнар Алла каршында гына тезләнәләр!

Баһадирны Казанга алып кайталар. Озак җәзалаганнан соң, шәһәр мәйданында кабыргасыннан асып үтерәләр.

Ул Казанда тәхетен түгел, ләхетен таба. Бәйсез татар дәүләтен

кабат торгызыр өчен башын сала.

Морат солтан!

Синең соңгы авазың безнең күкрәкләрдә сулкылдый. Олтанга әйләнгән токымыңа ни әйтергә теләдең?..

* * *

Бер ярдәм булмас, җиңелсәң
Тәхет өчен яуларда,—
Үз йөрәгеңә таянып
Күтәрелерсең дарда...

## Сәет батыр

(?—1722)

Сугышлардан башы чыкмаган Петр патшаның нәфесе үскәннән-үсә бара. Ул урысларның Һинд океанына кадәр җирләрне басып алуы турында хыяллана. Ә моның өчен күп корал кирәк. Ул татар җирләренә заводлар салдыра, анда күпләп урысларны күчереп утырта. Ләкин татарлар җиңел генә җиңелергә теләмиләр. Алар әле үзләренең шанлы чакларын, бөек дәүләтләр тоткан гасырларны онытып бетермәгәннәр. «Оныттырырга!» — дип уйлый патша. Моның өчен аларны чукындырырга, урыска әйләндерергә кирәк.

Илбасарлар мәчетләрне җимерәләр, мөселман авыллары янына зур-зур таш чиркәүләр салалар.

**Коллыктан да зур хурлык юк!**

Халыкның түземе бетә. Бу юлы аны Чаллы авылы кешесе Сәет батыр көрәшкә күтәрә. 1717 елның көзендә ул, үзенең яугирләре белән Чулман (Кама) аша чыгып, урыс гаскәрләренә каршы һөҗүм башлый. Татарларны көчләп чукындырган попларның гәүдәләре агач ботакларында чайкала. Казанга инде илле чакрым гына кала. Куркуга төшкән Петр патша Сәеткә каршы өстәмә гаскәр юллый.

Сәет көрәштәшләре белән казакъ даласына чигенә. Урыс патшасы казакъ ханыннан Сәет батырны тотып бирүен таләп итә. Тик хан никадәр тырышмасын, каһарман Сәет дошман кулына төшми.

Татарларга тәмам ачуы чыккан Петр патша Казанда урыс дәүләте өчен кораблар ясый башларга боера. Ә ко-

раб ясарга бик күп агач кирәк. Илбасарлар меңәрләгән татарны агач кисәргә дип кара урманнарга куалар. Күбесе шул урманнарда кабер тапкан бу кешеләрне лашманчылар дип атаганнар.

Ә бу вакытта Сәет казакъ даласында кылыч яный.

Тирәсенә үзе кебек качкыннарны җыя. Илбасарларга каршы яңа һөҗүмгә әзерләнә.

Петр патша, моны белеп алгач: «Сәетне тотып безгә бирегез»,— дип, казакъ ханына янә хәбәр сала.

Казакъ ханы шүрләп кала. Әгәр урыс патшасы Сәет сылтавы белән казакъ иленә бәреп керсә? «Тотып китерегез Сәетне!» — дип кычкыра хан...

Яугирләр, Сәет батырны эзләп, далага сибелә.

Бу сугышта Сәетнең иптәшләре кырылып бетә. Сәет батыр үзе исә бер кыяга менә.

— Мин азат! Богаулый алмассыз,— дип, яралы бөркеттәй, түбән ташлана.

* * *

Азатлык юлы газаплы.
Тик татлы да бу газап.
Чигенсәң, Сәетләр рухы
Алыр кебек бугазлап.

## Килмәк абыз

(?—1738)

«Абыз» дип элек татарлар абруйлы, хөрмәткә лаек укытучыларга, мөгаллимнәргә әйткәннәр! Нарыш улы Килмәк шундый кеше була. Ул шәкертләренә дин гыйлеме өйрәтә, Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен житкерә. Урысларның ислам динен мыскыл итүләре, мөселманнарны кешегә санамаулары аның йөрәген әрнетә. Ул Казан ханлыгын яңадан торгызу турында хыяллана. Бөтен гомерен шул юлга багышлый. Яшь егет вакытта ук Килмәк Морат солтан белән бергә Төркиягә бара. Төрек солтаныннан Моратны Казан ханы итеп тануын үтенә. Тик төрекләр бу үтенечкә колак салмыйлар.

Урыс илендә урыслар гына яшәргә тиеш! Илбасарлар шулай уйлый. Алар инде татар-башкорт җирләрен дә урыс иле — Россия дип саныйлар. Мөселманнарны урыска әйләндерер өчен, аларны чукындырырга, мәчетләрен җимерергә, үз телләрендә укытмаска кирәк. Киләчәктә монда бер генә татар да яшәмәскә тиеш, янәсе.

Тик нигәдер татарлар урыс булырга теләмиләр. 1735 елда алар

яңадан баш күтәрә. Яугирләрне  Күчем батырның улы Акай белән Килмәк абыз җитәкли.

Татарлар белән башкортлар урыс илбасарларына каршы бергәләп көрәшәләр. Илбасарлар бу ике бертуган халык  арасын күпме генә бозарга тырышмасын,  аларның ниятләре барып чыкмый.

Илбасарлар баш күтәрүчеләрне җиңә алмый. Дошман булдыра алмаганны үзебезнең сатлык җаннар эшли. Кыдрач белән  Әиткол дигән бәндәләр Килмәк абызны  урысларга тотып бирәләр.

Бу исемнәрне дә истә тотыгыз. **Гыйбрәт өчен халык үз сатлыкларын да онытмаска тиеш.**

Татар  илендә караңгылык тагын да куера. Яндырылган авыллар урынында кисәү башлары төтенли, алар өстендә буйсынырга теләмәгән меңәрләгән каһарманның җаннары адашып йөри. Урыс җирләренә коллыкка сатылган хатын-кызлар, бала-чагалар иңрәп көнбатышка атлыйлар. Себердә богау чыңнары ишетелә.

Уфа төрмәсендә Килмәк абыз үлем алдыннан соңгы догасын пышылдый...

* * *

Дога кылды Килмәк абыз,
Бит сыпырды теләк белән...
Тик дога да коткаралмый
Кардәшеңнең элмәгеннән.

## Алдар Исәнгилде

(?—1740)

Ул заман татар-башкортлар арасында иң бай кеше Алдар тархан була. Аның авыллары, җәйләүләре күп, иксез-чиксез болыннарда сигез мең аты утлап йөри.

Төркия белән сугышканда, урыс патшасы Петр яуга үзе белән Алдарны да чакыра. Алар бергәләп борынгы татар каласы Азакны алалар. Патша Алдарны алтын кылыч белән бүләкли. Ләкин, өенә кайткач, Алдар үз халкының урыслар тарафыннан изелүен тыныч кына күзәтеп тора алмый. Бераздан илбасарлар аның үз утарларын талый башлыйлар, кешеләрен үтерәләр, атларын куып алып китәләр.

Менә Алдарның өенә тарханнар, биләр, батырлар җыела.

— Җитте! — дип оран сала Алдар тархан, бала башы кадәр йод-

рыгын селки-селки.— Илбасар табаны астында тилмергәнче, җаным чыксын. Казан ханлыгын яңадан торгызабыз! Менә сезнең алда яңа хан — Морат солтан! Күчем ханның токымы.

— Урысларны җиңәр өчен, Кырым ханы белән төрек солтанының ярдәме кирәк,— ди Килмәк абыз Нарыш.— Без ярдәм сорап, Морат солтан белән алар хозурына барыйк.

Морат, ярдәм сорап, төрек солтаны Әхмәт янына китә. Ә Алдар тархан, Күчем батыр белән берләшеп, илбасарларга каршы яуга күтәрелә.

Төрекләр белән Кырым татарларына ярдәм сорап киткән Морат солтаннан хәбәр булмагач, Алдар көрәштәшләренә тагын бер «хан» тәкъдим итә: «Хаҗи солтан! Менә безнең яңа хан!»

— Нинди хан булсын, башкорт ич ул! — ди Күчем батыр, яңа «хан»ны танып.

Урыслар хан сайлап яткан татарларга каршы һөҗүмгә күчәләр. Алдар тархан исән калган гаскәре белән үз җирләренә — Агыйдел буйларына чигенә.

Үз утарында утыз еллап тыныч кына яши Алдар тархан. Халкын кыерсытсалар да, тешен кысып түзә.

Ә 1739 елда патша түрәләре халык исәбен алырга ниятлиләр. Илдә төрле сүзләр тарала, янәсе, юкка түгел бу, урыслар безне чукындырырга уйлый. Фетнә куба. Асыл егетләр янә атка менә. Алдар тархан да азатлык юлын сайлый. Чөнки ул гомере буе Казан ханлыгын торгызу турында хыяллана. Шуңа да баш күтәрүчеләр янына яңа хан алып килә: «Гәрәй солтан! Морат солтанның туганы»,— ди.

**Юл чыгар өчен дә юлбашчы кирәк**.

Соңгы сугышта яралы Алдарны илбасарлар кулга төшерә. Азатлыкка юл Минзәлә төрмәсендәге дарда төгәлләнә.

Алдар Исәнгилде! Истә тотыйк бу исемне.

* * *

Үлемне дә Алдар, диеп,
Исем бирделәр. Алдады —
Намусын алдамас өчен,
Мәңгелеккә башын салды.

# Батырша

(?—1761)

«Гали мулланың улы туган!» — дигән хәбәр Карыш авылында тиз тарала: хәзрәт белән бергә бөтен халык шатлана. Бәхетле ата

улына Габдулла Баһадиршаһ дигән озын исем куша. Аның киләчәктә татар-башкорт халкы өчен чыннан да Баһадиршаһ — Батырша булачагын алдан сиздеме икән әллә мулла?

Үсә төшкәч, аны Әлмәт янындагы Тайсуган мәдрәсәсенә укырга илтәләр. Ул гыйлемен арттыра, дөнья күрә. Үз халкының илбасарлар кулы астында калуына яшь егетнең йөрәге сыкрый. Урысларга сатылган татар-башкорт түрәләрен күреп, аның җанында үч алу теләге уяна.

Илбасарлар һәм аларның ялчылары татарларны көчләп чукындыралар, чукынмаганнарның җирләрен-суларын тартып алалар, хатыннарны, кызларны мыскыл итәләр. Халык атаклы Батырша мулла янына киңәшкә килә: «Сабыр итәр тәкатебез калмады... Атараыбыз-бабаларыбыз били торган оҗмахтай хуш җирләребезне ташлап китәбез»,— диләр алар.

«Үз җирләребезне ташларга түгел, аннан илбасарларны куарга кирәк!» — ди Батырша. Ул халыкны дошманга каршы яуга күтәрелергә өнди, өндәмә язып, аны шәкертләре аша тирә-юньгә тараттыра:

— Мөселман мөселманның ярдәмчеседер. Мине үзегез дип белегез!

Ләкин патшаның гаскәре зур, ялчылары күп. Алар баш күтәрүчеләрне тар-мар итәләр, үтерәләр, исән калганнарның телләрен, борыннарын, колакларын кисеп алалар. Урыслар тантана итә.

Батыршаны Петербургка тотып китереп, салкын таш зинданга ябалар. Тик аның рухы сынмый. Каһарман мулла төрмәдән патшага озын хат яза: «Безнең ук аткан саен куәтләнә... Ботакка кунган тиенне, сусарны атканда, ботагы белән өзеп төшерә».

Без әле бетмәдек, безнең көчебез әле бар. Батырша патшага шуны әйтергә тели.

**Рухы нык кешенең гомере дә анык**.

Таш зинданда алты ел вакыт уза. «Монда исән килеш черегәнче, алышта үлүең яхшы»,— дип уйлый мулла. Бервакыт сакчының ишекне ачуы була, Батырша тышка ыргыла, богаулы куллары белән почмактагы балтаны эләктереп, төрмә сакчылары өстенә ташлана. Берсе каплана идәнгә, икенчесе, өченчесе...

Менә таш идән акрын гына Батыршаның да йөзенә якынлаша. Ярсудан мулланың йөрәге ярылган була. Дошман белән алышып, аягүрә китә ул дөньядан...

Батырша! Син безнең йөрәгебезгә янә батырлык чаткысы сал.

* * *

«Биш сарыклык гайрәт кала
Әлсерәгән арысланда...» —
Һәм Батырша дошманына
Богавы белән ташлана.

# Бәхтияр Канкай

(XVIII гасырның икенче яртысы)

Бөтен далаларга, бөтен кала-салаларга хәбәр таралды: Әби патша ире, тәхеттән төшерелгәч, Оренбург далаларына качкан да, имеш, казакларны фетнәгә күтәргән. Хәзер тирә-юньдәге халык шул Питыр патша янына агыла, ди... Татарлар, башкортлар бер-берсенә шыпырт кына хәбәр сөйләделәр: Питыр патша мөселманнарны кимсетүче алпавыт урысларны, завод хуҗаларын дарга асарга кушкан икән...

Көзге караңгы төндә Бәхтиярның тәрәзәсен кактылар. Хуҗа сагаеп кына тәрәзәгә килде. Тышта берни күренми иде. Тавыш ишетелде.

— Мин бу, Габделкәрим. Күзкәй улы.

Бәхтияр ишекне ачты. Балалар уянмасын өчен пышылдап кына:

— Нинди җилләр ташлады? — дип сорады.

— Ишеткәнсеңдер, яңа патша бөтен халыкны Рәсәйгә каршы күтәрә.

— Дон казагы Пугачау ул,— диде Бәхтияр.

— Булмагае... Ул бөтен татарга азатлык вәгъдә иткән, тәхеткә менсәм, татарлар ил тотып яшәрләр иде, дип әйткән, имеш. Илбасарлардан котылабыз, ниһаять!

— Әйе, йоклап ятар вакыт түгел,— дип, Бәхтияр аның сүзен җөпләде.

**Ил тоткан халыкта гына кот була**...

Алар, таң белән җыенып, Пугачау янына Бирдә бистәсенә киттеләр. Егетлек юлы шулай башланды. ...Шул хәлләрдән соң күпме генә вакыт үтте, менә хәзер Бәхтияр Мамадышта гаскәрен барлый. Нократ, Чулман кичүләрендә аның яугирләре. Алар җәза отрядларының һөҗүмен аяусыз кире кага.

Бәхтияр борчулы. Ул Казаннан хәбәр көтә. Пугачауның төп көчләре Казанны алганнармы, юкмы?

Инде ул Пугачауга бер-бер артлы дүрт чапкын юллады. Алар

суга төшкән кебек югалдылар...

Дөбердәп ишек ачылды. Бәхтиярның ярдәмчесе Балтач Сәет йөгереп керде.

— Пугачау Казан янында җиңелгән! — дип кычкырды ул — безгә каршы хөкүмәт гаскәре килә. Без чолганышта!

— Яуга! — дип әмер бирде Бәхтияр.

Канкойгыч сугыш башланды. Караңгы төшкәч, исән калган берничә яугире белән, яралы Бәхтияр Мамадыш урманына кереп югалды.

Аны патша ялчылары бик озак эзләде, югалттылар... Халык кына югалтмады — инде ничә гасыр исемен күңелендә саклый.

* * *

«Бәхтияр егет — ир, имеш,
Буем бирмәм, ди, имеш».—
Шулай дип җырлаган халык
Хәтта егылган килеш.

Алмыш илтабар.....................
Кол Гали..........................
Бату хан..........................
Бачман...........................
Үзбәк хан.........................
Котби............................
Мәхмүд Болгари.....................
Сәйф Сараи........................
Туктамыш хан.......................
Идегәй...........................
Олуг Мөхәммәд хан..................
Мәхмүд хан........................
Ибраһим хан.......................
Нурсолтан........................
Мөхәммәд Әмин хан..................
Мөхәммәдьяр......................
Сәхиб Гәрәй хан....................
Сафа Гәрәй хан.....................
Сөембикә........................
Япанчы...........................
Кол Шәриф........................
Мәмеш-Бирде......................
Гали-Әкрәм........................
Җангали батыр.....................

Мәүла Колый......................
Хәсән Карачура.....................
Теләкәй — Күчем — Акай — Габдулла........
Морат солтан.......................
Сәет батыр.........................
Килмәк абыз........................
Алдар Исәнгилде....................
Батырша...........................
Бәхтияр Канкай.....................

Литературно-художественное издание

НАШ СЛЕД В ИСТОРИИ

**Зайдуллин** Ркаил Рафаилович

**КАЗАНСКАЯ КОРОНА**

Маленькие рассказы о великих людях X—XVIII веков

Казань. Издательство «Магариф». 2004

*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма

Әдәби-нәфис басма

БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

***Казанның 1000 еллыгына***

**Зәйдуллин** Ркаил Рафаилович

**ТАТАР ТАҖЫ**

X — XVlll гасырларда яшәгән олуг кешеләр турында нәни хикәяләр

Редакция мөдире *Л. Г. Шәрифуллина*
Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Р. М. Галимова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләр *Э. Ф. Нурмөхәммәтова, Л. Р. Вафина*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.04.2004. Форматы 70х90 1/16.
Офсет кәгазе. «Футурис» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7, 61.
Тиражы 3000 д. Заказ К 4/39.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http: //magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.